КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 декабрь г.Казань № 1217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 13 апрель, 294 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 20 май, 333 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче, 2018 ел, 20 февраль, 101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Югары һөнәр белеме бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластеры составына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән):

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 22 апрель, 311 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче, 2018 ел, 20 февраль, 101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Югары һөнәр белеме бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластеры составына, уникенче абзацны түбәндәге түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән):

«Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе».».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2013 ел, 19 август, 571 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының нефть-газ комплексы өчен кадрлар әзерләү буенча фәнни-белем бирү кластеры составына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче, 2019 ел, 2 сентябрь, 740 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аңа түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$6^1$. «Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы дәүләт педагогика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 6 апрель, 262 нче карары белән расланган Чаллы дәүләт педагогика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составының җиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 22 апрель, 315 нче карары белән расланган «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составының бишенче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 13 апрель, 294 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 29 декабрь, 1217 нче
карары редакциясендә)

«Казан милли тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластеры составы

«Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

«Бөгелмә машина төзелеше техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«В.П.Лушников исемендәге Казан нефть химиясе көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Спас тармак технологияләре техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе.